КУЗБАССТАН СӘЛАМ
Татарстан Президенты Кемерово өлкәсенә сәфәр кылды
> 2

ТӘМЛЕ ҖӘЙ
Татарстанда җиләк җыя башладылар
> 2

БДИ – 2022
Беренче нәтиҗәләр сөендерерлекме?
> 3

БӘЙРӘМ КАЙТАВАЗЫ
Киләсе очрашуларга кадәр!
> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 90 (28863) | Сишәмбе | 28 июнь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ТИК СОҢГЫСЫ ГЫНА БУЛМАСЫН

Татарстанда юл төзелеше эшендә тоткарлыклар юк. Килеп туган вазгыять әлеге тармакка тискәре йогынты ясамаган. Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин журналистлар белән очрашуда шулай дип ышандырды. Яңа юллар гына төзеп калмыйча, аварияләр санын да киметергә вәгъдә итәләр.

Национальные проекты.рф

Быел Татарстанда юллар төзелешенә 64 миллиард сум акча бүлеп бирелгән. Татарстан транспорт һәм юл хуҗалыгы министры урынбасары Артем Чукин сүзләренә караганда, әлеге акчаның 9,7 миллиард сумы «Куркынычсыз һәм сыйфатлы машина юллары» илкүләм проектын тормышка ашыруга тотылачак. Аның кысасында 54 чакрым озынлыкта яңа юл, 12 күпер төзеп, тагын 15ен төзекләндерергә җыеналар.

«Әлеге проект буенча каралган юл эшләре Казан, Чаллы һәм Түбән Кама кебек өч зур шәһәр агломерациясендә башкарыла. Аларның гомуми озынлыгы 2,5 мең чакрымнан артык. Алар барлык төбәк юлларын үз эченә алган», – ди министр урынбасары.

Килеп туган вазгыять юллар төзелешенә тамырдан үзгәрешләр кертмәгән. Артем Чукин сүзләренә караганда, илкүләм проект кысасында быелга планлаштырылган барлык юл эшләре дә график буенча алып барыла. Төзелеш материаллары кыйммәтләнү, техникага запчастьлар җитмәү кебек соңгы арада телдән төшмәгән проблемалар да юл төзелешенә тискәре йогынты ясамаган.

– Барыбызга да билгеле хәлләр юл төзелешенә дә күпмедер йогынты ясады, билгеле. Әмма барлык подрядчы юл-төзелеш оешмалары да бу сезонга ныклап әзерләнде. Нindидер кыенлыклар юк, эшче кулларга да кытлык күзәтелми. Төзелеш материаллары җитмәү, техника ватылу сәбәпле объектларда тоткарлыклар килеп чыкканы юк. Бүген барлык эшләр дә график буенча алып барыла. Кайбер урыннарда юл эшләренең 55 проценты башкарылган инде, – диде министр урынбасары.

Казандагы юллар да төзекләндереләчәк, дип ышандыралар. Аерым алганда, быел башкалада 8,4 чакрымлык 6 юл участогы яңартылачак. «Хәзерге вакытта Казанның Әмирхан, Четаев, Салмачы бистәсенең Үзәк урамында, Энергетиклар, Ершов һәм Көнбатыш урамнарында төзекләндерү эшләре алып барыла. Аның кысасында әлеге урамнарда асфальт яңарту, тротуарларны төзекләндерү, куркынычсызлык киртәләре урнаштыру, юл билгеләре, яктырткычлар, светофорлар кую каралган. Бу эшләргә барлыгы 1 миллиард сум акча бүлеп бирелде. Хәзерге вакытта башкала юлларында планлаштырылган эшләрнең 31 проценты тәмамланды», – ди Казанның тышкы төзекләндерү комитеты рәисе урынбасары Эдуард Вафин.

Илкүләм проект кысасында авылдагы юлларга да игътибар бирелә. Хәзерге вакытта республикадагы дүрт авылга илтүче юллар яңартылган инде. Моннан тыш Шәле – Баулы, түләүле Әлки – Әлмәт юлы да төзелә. «Инфраструктура кредиты хисабына хәзерге вакытта проектлау эше алып барыла. Аннары шуның нигезендә башкаладагы Горький шоссесы, Вознесение тракты белән «Салават Күпере» микрорайонына илтүче Осиново урамы төзекләндереләчәк», – ди Артем Чукин. Министр урынбасары Вознесение трактында да эшнең тулы куәткә алып барылуын искәртте. Аның беренче өлешен киләсе елга төзеп бетерергә планлаштыралар. Икенче өлешен төзүгә быел 3 миллиард сум акча бүлеп бирелгән.

Артем Чукин сүзләренә караганда, Татарстан юлларында һәлакәтләр иң күп теркәлә торган 68 урын исәпләнә. Шуларның 22се – аеруча куркынычлар рәтендә. Ел башыннан бу урыннарда ким дигәндә 3 юл һәлакәте теркәлгән. «Мондый куркыныч участокларда юл һәлакәтләрен башка булдырмау өчен барлык чаралар да күрелә. Аерым алганда, тротуарлар ясала, ел дәвамында 64 чакрым юлны яктырту планлаштырылган. Моннан тыш аерым участокларда юл бүлгеч киртәләр, ясалма тигезсезлекләр дә пәйда булачак», – дип ышандырды министр урынбасары.

Юлны төзү генә түгел, аның сыйфатлы булуы да мөһим. Яшерен-батырын түгел, күп очракта яңа төзелгән, төзекләндерелгән юллар бер елга да чыдамый. Юлда хасил булган чокырлар аеруча үзәккә үтә. «Главтатдортранс» оешмасы җитәкчесенең беренче урынбасары Александр Куканов та аларны иң авырткан җир дип атый.

– Кызганыч, бу проблеманы әле һаман ахыргача хәл итеп бетереп булмый. Без кирәкле җиһаз алып, махсус тикшерү уздырдык. Аның нәтиҗәләре буенча материалларга катгыйрак таләпләр куябыз. Әйтик, асфальт-бетон катнашмасы җитештергәндә материалларны Уралдан кайтартабыз. Кызганыч, үзебездә андый чыдам, нык юл төзелеше материаллары юк. Әмма шул ук читтән кайтартылган материалларның да сыйфаты төрле була. Шуңа күрә юл катламын ныгыту, чокырларны булдырмау өчен тагын берничә материал куллана башладык. Соңгы өч елда Казан, Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама кебек зур шәһәрләрдәге юлларның машина иң күп йөри торган өлешләре әнә шундый яңа, чыдамрак катнашма ярдәмендә төзекләндерелә. Әмма әлеге ысул ярдәмендә дә юлдагы чокырлардан ахыргача котылып булмый әле, – ди Александр Куканов.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Укытучыларга багышлана

Владимир Путин 2023 елны илдә Укытучы һәм остаз елы дип игълан итү турында Указга кул куйды. Россия Хөкүмәтенә 3 ай эчендә Укытучы һәм остаз елын уздыру буенча оештыру комитетын булдыру, составын раслау йөкләнгән. Министрлар Кабинетына шулай ук аны үткәрү планын эшләргә кирәк булачак.

Исегезгә төшерәбез: киләсе елның Укытучы һәм остаз елы булачагы турында 2021 елның октябрендә белдерелгән иде. Президент бу карарны 2023 елда Россиядә фәнни педагогикага нигез салган Константин Ушинскийның тууына 200 ел тулу белән бәйләп аңлатты.

Йортлар яңара

Татарстанда күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерү буенча быелгы программа 37 процентка үтәлгән. Бүгенгә республикада 31 йорт яңартылган, 69ында лифтлары алыштырылган. Тагын 68 йортта төзекләндерү эшләре ахырга якынлашып килә. Төзелеш министры Марат Айзатуллин Президент Рөстәм Миңнеханов үткәргән киңәшмәдә әйтүенчә, торак йортлардан тыш, мәктәпләрдә, медицина оешмалары, мәдәни объектларда да ремонт эшләре алып барыла. Шулай ук урамнарда яктырткычлар алыштырыла, суүткәргечләр, газ, инженерлык челтәрләре реконструкцияләнә.

Торак-коммуналь хуҗалык өчен түләүгә килгәндә, узган айда түләүләрне җыю 98,1 процентка җиткән. Бу – узган елдагы күрсәткечтән 0,6 процентка күбрәк. Хәзерге вакытта Татарстанда коммуналь хезмәтләр буенча бурыч күләме 8,9 миллиард сум тәшкил итә.

Трамвайда йөрү арзанрак

Казанда трамвайдан трамвайга бушлай күчеп утыру өчен «Трамвай 60 минут» дигән яңа тариф гамәлгә кертелә. Казан башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илдар Шакиров әйтүенчә, мондый тарифлы транспорт картасы белән бер үк юнәлештә йөрүче бер трамвайдан икенчесенә 1 сәгать эчендә күчеп, монысында инде түләүсез барырга мөмкин. Шул ук вакытта транспорт маршрутының нинди булуы һәм күчеп утырулар саны мөһим түгел. Бу очракта юл өчен түләү 31 сум тәшкил итә.

Яңа тариф 2 июльдән гамәлгә керәчәк. Илдар Шакиров аңлатып үткәнчә, яңалыктан файдалану өчен транспорт картасын сатып алып, яңа тарифны сайларга яисә иске картаны шушы тарифка күчерергә мөмкин. Бу тарифка көйләнгән картага акчаны инде хәзер үк салырга була.

wiki2.org

Нәтиҗә

Без кемгә кирәк?

Рособрнадзор 2022 елгы Бердәм дәүләт имтиханының беренчел нәтиҗәләрен игълан итте. Әйтик, рус теле буенча уртача балл – 68,3, физикадан – 54,1, тарих фәненнән – 57,95. Гади итеп әйткәндә, фәннәрне кичәге мәктәп балалары «дүртле»лек белә.

Имтихан нәтиҗәләре баланы да, югары уку йортын да канәгатьләндермәсә, нишләргә? Ягъни кечкенә балл дип нинди күрсәткечне атыйлар?

Рособрнадзор ел саен аларның минималь дәрәҗәсен билгели. Әйтик, җәмгыять белеме өчен ул – 45, информатика өчен – 44, география, рус теле, рус әдәбиятыннан – 40ар, математика, биология, химия, физика – 39, тарихтан – 35, чит телләрдән – 30 балл.

Укучыны шуннан да ким булган балл белән, билгеле, бер генә уку йорты да кабул итәргә әзер түгел. Шулай да имтихан нәтиҗәләре белән югары уку йортына, иң мөһиме – бюджет урынына эләгү өчен күпме балл кирәк соң?

2020 елда Икътисад югары мәктәбе БДИның уртача баллары буенча югары уку йортлары исемлеген төзегән иде. Аның нәтиҗәләре буенча беренче урынга Мәскәү физика-техник институт чыккан. Биредә уртача балл 97,6ны тәшкил иткән. Икенче урында – 96,2 балл белән Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты, өченче урында – 95,7 балл белән Иннополис университеты.

Нигездә, өч фән буенча балларны кушып санаганда, кимендә 270 балл җыйсаң, яхшы санала. Уртача дип – 150дән 200гә кадәр, ә түбән дип 150 баллдан да кимрәк күрсәткечне атый белгечләр.

Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы әзерләгән «Поступай правильно» хезмәтеннән файдаланып, иң кечкенә баллар белән дә кайсы уку йортына кереп буласын ачыклап карадык.

Имтиханда 115 балл җыйдык (рус теле – 40, чит телләр – 35, математика – 40), Казандагы уку йортын сайларга телибез, көндезге уку бүлегендә укырга җыенабыз дигән «хыял»ларыбызны махсус эзләү тасмасына яздык. Программа республиканың өч югары уку йортын чыгарды. Болар – Казан федераль университеты, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты һәм Туполев исемендәге Казан илкүләм тикшеренү техник университеты.

Татарстан белән генә чикләнмичә, минималь баллар белән илнең теләсә кайсы дәүләт вузының «ишеге»н шакып карарга булдык. Программа дистәләгән вариант чыгарды. Әмма абитуриентка игътибарлы булу сорала. Уртача баллны бу хезмәткә ышанып түгел, вузның рәсми сайт, белдерүләрен карап тикшерергә кирәк.

Күпләр, БДИ нәтиҗәләре канәгатьләндерерлек булмаса, университетка якын да килмәскә кирәк, ди. Иң яхшысы – бер ел «ял» алып, әзерләнергә, белемнәрне яңартырга. Тик, тәҗрибә күрсәткәнчә, күпләр моңа риза түгел.

Иң яхшысы – балларым түбән булды, дип төшенкелеккә бирелмичә, белем алу җаен барлау. Билгеле, БДИ нәтиҗәсенә карамастан, түләп укырга әзер булучылар өчен мөмкинлекләр чикләнмәгән.

Шунысы да куандыра: аларның күпчелеге югары уку йортлары белән тыгыз элемтәдә эшли, димәк, укып бетергәч, кичәге көллият укучылары белемен ташламалы шартларда вузда арттыру мөмкинлегенә ия.

Теманың дәвамы – 3 биттә >

Сүзгә-сүз

Вячеслав ВОЛОДИН, Дәүләт Думасы Рәисе:

Бүген безнең солдатлар, офицерлар Россия иминлеген саклый, ватандашларыбызны коткара. Без алар алдында намуслы булырга тиеш. Алар илнең, халыкның терәк булуын аңларга тиеш. Шуңа күрә махсус операция турындагы мәгълүматны бозып җиткерә, әле моның өчен студентлар каршысында сөйләргә кафедраны да куллана икән, андыйлар эшеннән китәргә тиеш.

(Парламент утырышында чыгышыннан)

ТАТАРСТАНДА – ЯШЬЛӘР

2022 ел башына караган мәгълүмат буенча Татарстанда 14–35 яшь аралыгында булган 1051,4 мең кеше яши.

Татарстан халкының **27,1%** >> яшьләр

77,8% >> шәһәр яшьләре

22,2% >> авылдагы яшьләр

33,9% >> Казанда яши

*Татарстанстат мәгълүматлары буенча

Салкын җәй

Бу атнада тагын салкынайта: көндез һава температурасы +19 градустан артмаячак. Гомумән, июнь азагы – июль башында салкынча коры һава көтелә.

Республика Гидрометеоүзәгеннән хәбәр ителгәнчә, чәршәмбе – 29 июльдә көндез +14…+19 булса, төнлә һава температурасы бөтенләй дә +4…+9 градуска кадәр төшәчәк. Пәнҗешәмбе – 30 июньдә кыска вакытлы яшенле яңгыр, секундына 17 метрга кадәр тизлектә көчле җил. Көндез +17…+22 градуска кадәр җылы булачак.

Синоптикларның башлангыч фаразына караганда, җомга – 1 июльдә бераз явым-төшемле һава көтелә. Челлә аеның беренче көнендә көндезге сәгатьләрдә термометрның терекөмеш баганасы нибары +14…+19 градусны күрсәтәчәк. Шимбә – 2 июльгә һава торышы яхшыра башлаячак, яңгырлар туктаячак. Көндез +19…+23 градуска кадәр җылытачак.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

АБОРТЛАР ТИРӘСЕНДӘ ЗУР ҖӘНҖАЛ

Планетакүләм зур турбулентлык көчәюен дәвам итә. Үткән атнада вакыйгалар үсешен шул сүзләр белән бәяләп булыр иде. Кытай компартиясе Үзәк комитеты идарәсендә чыгучы Economic Daily газетасы биткоин бәясе нульгә кадәр түбәнәергә мөмкинлеге турында белдерде. Эш бер криптовалюталарда гына булса, бик ис тә китмәс иде, әмма перспективада барлык активлар да шул юнәлештә хәрәкәт итәләр.

Безне бәясен югалткан фатирлар, бер тиенгә дә кирәкмәгән җитештерү цехлары, зур мәтәлчек аткан фонд базары һәм башка күңелсезлекләр көтә. Икътисади кризис үзе генә килсә, алай ук куркыныч та булмас иде, әмма ул зур конфликтлар төенен төйни, бөек һәлакәткә таба якынлаштыра. Пекинның Франциядәге илчесе: «Кытай Тайваньны теләсә нинди чаралар ярдәмендә, шул исәптән сугыш юлы белән булса да кайтарып алачак», – дип белдерде. Белдерү, әлбәттә, Украина конфликты тирәсендә атом-төш күсәген болгаган шикелле куркыту чарасы гына. Күк асты илендә барган сызландыра торган икътисади вазгыятьтән халыкның игътибарын читкә юнәлдерү өчен яңгыратыла.

Кызганычтыр, зур бәрелеш сызыгы Көнбатыш аша уза. Европада һәм, шул исәптән Россиядә дә, икътисади кризис кискенрәк бара, Якын Көнчыгышта һәм Африкада зур ачлык белән кайтаваз бирергә җыена. Көнбатыш дәүләтләре калкып чыккан проблемаларда беравыздан Россияне гаеплиләр. «Көнбатыш санкцияләре түгел, Россиянең Украинага бәреп керүе планетада ачыгучыларның 40–50 миллион кешегә артуының сәбәбе булып тора», – дип сөйләде АКШның Дәүләт секретаре Энтони Блинкен үткән җомгада Берлинда. Германиянең Гармиш-Паркенкирхен районындагы Эльмау замогында «Зур җиделек»нең (G7) өч көнлек саммиты башланды. Лидерлар очрашуы бертавыштан Россиягә каршы карарлар җыелмасын кабул итүне, барлык бәлаләрдә дә Мәскәүне гаепләүне күздә тота. Украина мәйданындагы конфликтның дәвамлы булуы һәм озакка сузылуы Көнбатыш өчен сулар һава кебек кирәк, чөнки ул проблемаларга сылтау буларак хезмәт итә. Бәяләр күтәрелдеме, өйләрдә суыкмы, эшсезлек артамы – Мәскәүгә таба төртәсең дә күрсәтәсең.

Россиягә каршы зур коалиция туплау һәм тиңсез басым ясау зур сәясәткә әйләнеп бара. Иордания хакимиятләре король Абдалла II җитәкчелегендә Якын Көнчыгышта НАТОга охшаган зур хәрби блок төзү идеясен этәрәләр. Яңа «НАТО» Иранга каршы аркадашлык буларак формалашырга тиеш булса да, аны киләчәктә Россиягә каршы көч рәвешендә дә файдаланырга тырышачаклар.

Лидерлар аркадашлык мәсьәләләрен тикшергәндә, АКШта – глобальләштерүнең төп форпосты булган илдә яңадан зур протестлар кыза. Илнең Югары суды Америка хатыннарының абортка булган гарантияләнгән хокукын бетерде. Җәнҗал шул нигездә чыкты. Илнең күп кенә штатларында йөклелекне ясалма рәвештә өзүгә тыюлар бар иде инде. Югары суд карарыннан соң алар тулы көченә керә. «Российская газета» әлеге уңайдан: «Бу карар АКШта милли җир тетрәүгә тиң», – дип язды. Байден абортлар яклы. Закон әһелләре исә каршы. Бостон, Вашингтон, Лос-Анджелес һәм башка зур шәһәрләрнең урамнарында меңләгән протест белдерүчене җыйды ул карар. Теш сызлаганда, бармакны ишеккә кыссаң, беренче авырту онытыла бит. Янкилар бер проблеманы икенчесе ярдәмендә оныттыруның шул ысулын кулланалар.

Россиядә

БӨЕК РЕЦЕССИЯ КҮЛӘГӘСЕНДӘ

Дөньякүләм бара торган икътисади тетрәнүләр Россиядә бөтенләй башка форматта чагылыш таба. Без яшәгән ил үзенең иң яңа тарихында беренче тапкыр бәяләр төшүе – дефляция белән йөзгә-йөз, күзгә-күз очраша. Артык җитештерү кризисы дип аталган нәрсә җитештерүчеләрнең кабыргасын саный башлады.

Вазгыять үткән елгының бөтенләй капма-каршысы: фатирлар сатылмый, төзелеш материалларына бәяләр төшә, сыер ите очсызлана… Фермерлар, әйтик, сыер итен пошлинасыз импортлаудан риза түгел, чөнки чик аша кертелгән ит 25 процентка арзан. Доллары да безгә үч итеп очсызлана бит аның. Терлек азыгы исә кыйммәт, авыл хуҗалыгы техникасы да арзан түгел, җитмәсә, запчастьлар дефицитта һәм бәяләре буй җитмәслек. Менә шундый шартларда итне арзанга сатып кара син. Берсүзсез бөләсең.

Базарлар кысылуы, Европа белән озак еллар буе килгән сәүдә элемтәләренең өзелүе җитештерүчеләрне тәмам аяктан егарга җыена.

Федераль хөкүмәт белән Үзәк банк арасында яшерен көрәш бара. Чиновниклар акча станогын эшләтеп, сумны очсызландыруны таләп итәләр, Нәбиуллина конторасы әлегә моңа каршы. Төп ставканы төшерү идеясен куәтләүчеләр саны да арта. Соңгысы бизнес өчен файдалы булыр иде, әлбәттә. Хөкүмәт тагын бер нәрсәне алга этәрә – кредитлаштыруны арттыруны яклый. Әмма менә бу соңгы теләккә дефляция аяк чала. Бәяләр төшәргә торганда, нигә дип әле бурычка алып, кыйммәткә фатир алырга дигән фәлсәфә өстенлек ала башлый. Аннан соң элек алган кредитларын түли алмаучылар саны да арта. Җитештерү кими икән, эшсезлек тә артачак дигән сүз бит инде. Әнә-менә эшсез калам дип куркып яшәгәндә, ничек процентка әҗәт аласың… Кесәдә акча булганда да, эчке тавыш ашыкмаска, сабыр итәргә, бәяләрнең тагын да төшүен көтәргә чакыра. Сатып алучылар өчен ләззәтле, куандыра торган күренеш ул – дефляция.

Әмма җитештерүчеләр өчен газапка әйләнә, инвестиция ясау теләген юкка чыгара. Иткә бәя төшкәндә, нигә дип үгез сатып алырга әле дигән сорау тумый калмый. Җитештерүчеләрнең акчасызлыгы мәйданга чыга: хезмәт хаклары түләп булмый башлый, яңа җиһазлар сатып алу өчен акча юк, җитештерелгәнне кая куярга белмисең. Бюджетка бик каты китереп суга бу вазгыять. Финанс министрлыгын җитәкләгән Силуанов: «Алдагы ике елда Россия бюджеты белән бәла», – дип әйтеп өлгерде инде. 2025 елга кадәр бюджетка ел саен 1,3 триллион сум акча җитмәс дип көтелә. Углеводородларның гадәттән тыш югары бәясе дә коткармый бюджетны.

Проблеманы базарларны киңәйтү аша гына чишеп булыр иде. Әмма товарларны Азиягә ташу бик кыйммәткә төшә, логистика дигән нәрсә чабудан тота. Дефляция озакка барырмы, әйтүе кыен. Вәләкин акча басып, инфляция тәгәрмәчен әйләндерү дә коткармаячак. Бер бәлане икенчесе белән алыштыру гына булачак.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

БӘРӘКӘТЛЕ СӘФӘР

Саха (Якутия) Республикасында якут халкының Ысыах бәйрәмендә катнашканнан соң Татарстан Президенты Кемерово өлкәсенә юл тотты. Биредә ул икенче мәртәбә оештырылган Халыкара шахтерлар Сабан туен карады. Ике төбәк арасында килешү имзаланды.

Кемерово өлкәсендә 40 меңнән артык татар яши. Кузбасс татарлары милләттәшләребез – Социалистик Хезмәт Геройлары Шәех Зәйнетдинов, Гыйльметдин Идрисов, Советлар Союзы Герое Хәмзә Мөхәммәдиев, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гакый Фазалов, Россиянең атказанган табибы, Кемерово өлкәсенең Мактаулы гражданы Илгиз Галиев һәм башка кешеләр белән горурлана. Узган ел биредә тәүге мәртәбә Халыкара шахтерлар Сабан туе узды. Быелгысына Россия төбәкләреннннән, шулай ук Донбасстан, Казахстан һәм Кыргызстаннан шахтерлар килде. Новокузнецкида узган бәйрәмне Татарстанның Лениногорск районы ярдәме белән оештырдылар.

150 милләт вәкиле катнашында «Дуслык әйлән-бәйләне» белән башланган бәйрәмдә кунакларны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм әле узган атнада гына Ульян һәм Казандагы бәйрәмнәрдә кунак булган Кемерово өлкәсе губернаторы Сергей Цивилев котлады. Киләсе елда Федераль Сабан туе да Кемерово өлкәсендә узачак.

tatarstan.ru

Уртак эшләр күп булачак. Алар хакында Рөстәм Миңнеханов белән Сергей Цивилев катнашында узган очрашуда фикер алыштылар. Бүген ике арадагы сәүдә әйләнешенең күләме якынча 2,3 млрд сумны тәшкил итә. Татарстан Кузбасска йөк автомобильләре һәм автобуслар, шиннар, дизель ягулыгы һәм бензин, азык-төлек, җиңел сәнәгать продукциясе, медицина җиһазлары һәм башка товарлар җибәрә. Кемерово өлкәсеннән металл, күмер һәм кокс, медицина җиһазлары һәм коммуналь хезмәтләр өчен техника алып кайталар.

Татарстан Президенты билгеләп үткәнчә, республика инде бүген үк нефть химиясе һәм машина төзелеше предприятиеләре, халык кулланышы товарлары һәм көнкүреш химиясе продукциясен күбрәк җибәрә ала. Икътисадның төрле тармакларын цифрлаштыру һәм импортны алыштыру мәсьәләләрен хәл итүдә, мәгариф тармагында хезмәттәшлек итәргә әзер. Очрашу ахырында яклар 2022–2024 елларга сәүдә-икътисади, фәнни-техник, социаль, мәдәни һәм башка өлкәләрдә хезмәттәшлек итү турында Кемерово өлкәсе администрациясе Коллегиясе һәм Татарстан Хөкүмәте арасында килешүне гамәлгә ашыру буенча чаралар планын имзалады.

Рөстәм Миңнеханов Россиядә Haier вәкиллеге башлыгы, Россиядә Haier бизнесларын үстерү буенча директоры Людмила Романова белән очрашты.

Алар Чаллыда Haier проектларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча фикер алыштылар. Компания индустриаль паркны үстерү эшен дәвам итә. Бүген аның территориясендә кер юу машиналары заводы, көнкүреш техникасы заводы һәм әзер продукция склады эшли. 2021 елда тагын 2 завод (штампланган эшләнмәләр заводы, суыту һәм туңдыру җиһазлары җитештерү буенча «акыллы завод»), шулай ук хезмәткәрләр өчен тулай торак төзелеше башланган. Моннан тыш, 2016 елдан башлап «Мастер» КИП территориясендә суыткычлар җитештерү заводы эшли. Haier компаниясе тарафыннан барлыгы 1,7 мең яңа эш урыны булдырылган.

***

Хөкүмәт йортында булган киңәшмәдә, Рөстәм Миңнеханов узган атнада РФ Дәүләт Советы Президиумы утырышында Россия Президенты Владимир Путинга тәкъдим ителгән төзелеш тармагын һәм ТКХны үстерү стратегиясе турында сөйләде.

Билгеле булганча, Татарстан Президенты РФ Дәүләт Советының Төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык, шәһәр мохите юнәлеше буенча комиссиясен җитәкли. Утырышта ул төп чыгыш ясаучыларның берсе булды. «Ил Президенты төбәкләр, шул исәптән Татарстаннан кергән тәкъдимнәргә уңай бәя бирде», – диде Рөстәм Миңнеханов. Узган атнада Владимир Путинның күрсәтмәсе буенча РФ Хөкүмәте ташламалы ипотека ставкасын 7 процентка кадәр киметү турында карар чыгарды. Татарстан Президенты әйтүенчә, әлеге чара кешеләргә үзләренең торак шартларын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк һәм төзелеш секторына сизелерлек ярдәм итәчәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТИЗЛЕКНЕ ЙӨГӘНЛИСЕ

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының Татарстан буенча идарәсе мәгълүматларына караганда, ел башыннан электр самокатында йөрүче 735 кеше җаваплылыкка тартылган. Сәбәпләре төрле. Иң аяныч – авария очраклары да бар.

Ел башыннан республикада шушы транспорт чарасы катнашында 9 юл-транспорт һәлакәте теркәлде, 9 кеше зыян күргән. Куркыныч очракларның дүртесе прокатка алып торылган электр самокатын иярләгән кешеләр катнашында булган. Аварияләрнең өчесе электр самокатчыларының гаебе аркасында килеп чыккан.

Татарстан башкаласында электр самокатын иярләп йөрүчеләр апрель азагында ук күренә башлады инде. Билгеле булганча, шәһәрдә электр самокатын прокатка биреп торучы 500 пункт эшли. Әлеге транспорт чарасында йөрү сезоны башлануга хастаханәгә мөрәҗәгать итүчеләр турында да ишетелә башлады. Әйтик, өч баланың бу төр транспортта хәрәкәт иткәндә егылып имгәнүе турында хәбәр иткәннәр иде.

Гадәттә, электр самокатында йөрүчеләр нинди кагыйдәләрне санга сукмый соң? Белгечләр әйтүенчә, күп очракта алар машина юлында хәрәкәт итә, светофорга игътибар итми, юлда йөрү кагыйдәләрен боза, рөхсәт ителмәгән урыннарда йөри. ЮХИДИ вәкилләре электр самокатында хәрәкәт итүчеләргә юлда йөрү кагыйдәләрен бозган өчен 929 штраф язган инде.

Эчке эшләр министрлыгы вәкилләре уңайлы, беренче карашка куркынычсыз тоелган транспорт чарасында йөрү кагыйдәләрен истән чыгармаска киңәш итә. Әйтик, самокатта хәрәкәт итү өчен билгеләнгән махсус урыннарда гына йөрергә, автомобиль юлына чыкмаска, куркынычсызлык чаралары турында онытмаска – шлем, тез, терсәкне саклый торган махсус җайланмалар кияргә. Шулай ук самокатка берничә кешенең атланып йөрүе дә рөхсәт ителми.

ЮХИДИ идарәсе Татарстан башкаласында электр самокатында хәрәкәт итү өчен билгеләнгән тизлек дәрәҗәсе турында да искә төшерә. Бу гадәти урыннарда – сәгатенә 20 чакрым, кеше күпләп җыела торган урыннарда һәм белем бирү оешмалары тирәсендә сәгатенә 10 чакрым. Шулай ук Казанның 24 урамында бу транспорт чарасында йөрү чикләнгән.

ҺАВАДА – ҖИЛӘК ИСЕ

Көннәр кояш, җылылык белән артык иркәләмәсә дә, җиләк исе чыга башлады. Эре хуҗалыклар бакча җиләгенең беренче уңышын җыя. Димәк, чын-чынлап җәй җитте дип әйтергә җирлек бар. Татарстанда кайсы хуҗалыкларда бакча җиләге үстерәләр? «ВТ» хәбәрчесе аларны җыю, китереп бирү шартлары һәм бәяләрен белеште.

Фермерлар, хуҗалык җитәкчеләре белән сөйләшкәннән аңлашылганча, әлегә беренче уңыш кына җыела. Чөнки җәй соңарып килү сәбәпле, уңышны да озаграк көтәргә туры килгән быел. Мәсәлән, Яшел Үзән районының Зур Яке авылында җиләк үстерү белән шөгыльләнүче Динар Сабитов сүзләренчә, әлеге хуҗалыкта да беренче уңышны узган атнада гына җыя башлаганнар. Җимешләре бар үзе, тик кызарып пешәр өчен кояш җитми, ди ул.

– Өч гектар җиребез бар. Шуннан җиләк җыеп, халыкка сата башладык инде. Күптәннән сораучылар бар. Тик әлегә барысына да өлгертеп булмый. Һава торышының уңай булуы кирәк. Без химик препаратлар белән мавыкмыйбыз. Булганы җитә, дип эшлибез, – диде Динар Сабитов.

Хуҗалык башлыгы сүзләренә караганда, җиләкнең бер килограммын 300 сумнан саталар. Гомумән, Яшел Үзән районының Зур Яке авылында җиләк үстерү белән шөгыльләнүче дүрт-биш хуҗалык барлыгы ачыкланды. «Көндәшлек мине куркытмый», – диючеләр арасында «Шакиров» хуҗалыгы җитәкчесе Руслан да бар. Эшмәкәрнең җиләк плантацияләрен шулай ук Биектау районының Айбаш авылында да күрергә мөмкин.

– Җиләк бар, пешә башлады. Быел, кояшы булса, җиләк уңышы яхшы булырга тиеш. Менә үзебез бүген икенче уңышка кердек. Биектау районында әллә ни мактанырлык уңышларыбыз юк, чөнки ярдәм итү урынына күбрәк аяк чалу белән очрашырга туры килә. Ә менә Зур Яке авылында рәхәтләнеп эшләр өчен мөмкинлекләр тудырылган. Авыл советы башлыгы Фирая апа Фәйзуллинаның ярдәмен тоеп эшлибез, – диде ул.

«Шакиров» хуҗалыгында үскән җиләкләрне 330 сумнан сатып алырга мөмкин. Зур Яке авылында халыкка җиләкне җыеп бирсәләр, Биектау районының Айбаш авылында исә кешеләрнең үзләренә җыеп алу мөмкинлеге дә тудырылган. Бу очракта бер килограмм җиләк бәясе – 200 сум.

– Күп кеше җиләк җыюдан ләззәт ала, рәхәтлек кичерә. Шуңа күрә уйлаштык та шундый мөмкинлек тудырырга булдык, – ди эшмәкәр.

Шулай ук Биектау, Казанга китереп тә саталар икән. Тик сораучы күп булгач, өлгертеп кенә булмый, ди Руслан.

ТАТАРСТАНДА ҖИЛӘК ҮСТЕРҮЧЕ БАШКА ХУҖАЛЫКЛАР

- **«Җиләк аланы» («Ягодная долина») хуҗалыгы**
  (Әлмәт районының Ямаш авылы,
  Яшел Үзән районының Зур Яке авылы.)
  Җиләкнең бер килограммы – 500 сум.
- **«Ягодар» җиләк фермасы**
  (Минзәлә районының Яңа Александровка авылы.)
  Бер килограммын – 450 сумнан,
  3 килограммлы бер тартманы 1350 сумнан саталар.
- **«Ялалетдинов» фермер хуҗалыгы**
  (Кама Тамагы)
  Җиләкнең бер килограммы – 450 сум.
- **«ТатЯгода» хуҗалыгы**
  (Яшел Үзән районының Олы Карагуҗа авылы).
  Җиләк бәясе – 350–500 сум.

– Берни дә эшләтеп булмый. Кемдер өметләнеп килә дә сатып алырга өлгерми кала. Үпкәләп китүчеләр дә юк түгел. Хәлне аңлап, сабыр итүчеләр дә бар, – ди хуҗалык җитәкчесе.

Буа районының Бик-Үти авылында Миләүшә һәм Җәмил Дәүләтшиннар хуҗалыгында да җиләкләр өлгергән. Кызлары Лилия әйтүенчә, гаилә җиләкчелек белән өч ел шөгыльләнә. Бер гектар җирдә җиләкнең җиде төрле сортын үстерәләр.

– Башка елларны ремонтант сортларның беренче уңышын июнь башында җыя башлый идек, – ди ул. – Быел бер айга соңара. Башта җиләкләр үсеп китә алмады, аннан чәчәк атмады. Шулай итеп, беренче уңышны узган атнада гына җыеп алдык. Әлегә мул уңыш булырмы, юкмы – анысын әйтеп булмый. Җиләк бар үзе, пешәр өчен кояшлы көннәр дә кирәк. Бер айга соңга калгач, җиләк бирү вакыты да кыскара дигән сүз. Ремонтант сортлар көзгә кадәр уңыш бирә бит. Шуңа күрә көзнең ничек килүеннән дә тора.

Лилия сүзләренә караганда, алар бүген җиләкнең бер килограммын шулай ук 300 сумнан сата. Әлегә бары тик үзләре генә әзерләп бирә. Соңрак кешеләр үзләре дә килеп җыя алачак.

Руслан Шакиров: «Җиләк сораучы күп, өлгертеп булмый», – ди.

– Җиләккә сорау зур. Үзебезнең районнан да, күршеләрдән дә күп киләләр. Күпләп сату нокталары белән дә яхшы эшлибез, – диде ул.

Лилия әйтүенчә, җиләк үстерү – мәшәкатьле эш. Вакытында карарга, тукландырырга, су сибәргә кирәк. Бәяләре дә базар шартларына карап үзгәрә.

Шулай итеп, алда телгә алган хуҗалыкларда җиләкнең бер килограммын 300–330 сумнан саталар. Тик, җиләкчеләр әйтүенчә, гомумән республика буенча бәяләр 350–500 сум тирәсендә тирбәлә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕЛЕМ ЯРЫШЫ

БДИ – 2022

Бердәм дәүләт имтиханының төп этабы тәмам. Хәзерге вакытта кабат имтихан тапшырырга теләүчеләр өчен өстәмә көннәр билгеләнде. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәр иткәнчә, төгәл нәтиҗәләр июль уртасында игълан ителәчәк. Әлегә имтиханнарда 100 балл туплаган 189 укучыбыз белән горурлана алабыз.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«5ле» дә, «2ле» дә бар

Быел республикада 11 нче сыйныфны 16 меңгә якын укучы тәмамлады. Рус теленнән уртача балл 72,82не тәшкил итә. Чик баллны 19 укучы үтә алмаган. Математика (база) сынавында 7693 укучының 80гә якыны «2ле» алган. Шул ук вакытта 99 проценты биремнәрне уңышлы башкарган. Уртача билге – 4,39. Математикадан профиль имтиханын 7977 укучы сайлаган булса, 357 укучы «койрык» алган. Уртача балл – 64,06. Физиканы сайлаучылар – 2675 кеше. Бу фәннән уртача балл – 59,30. Тарихтан 1650 укучының 40ының эше начар дип табылган. Уртача нәтиҗә – 64,42.

Өстәмә көннәрдә рус теленнән кабат имтихан тапшырырга 524 кеше килгән. Алар арасында узган елгы укучылар да, быел нәтиҗәдән канәгать булмаучылар да, «2ле»сен төзәтергә килүчеләр дә бар. Башка фәннәрдән дә кабат тапшырырга мөмкин.

Районнардагы мәгариф бүлекләрендә дә соңгы имтиханнар – биология, информатика, инглиз теленнән нәтиҗә көтәләр. Кайбыч районы мәгариф идарәсе башлыгы Илмас Хәмидуллин әйтүенчә, районда мәктәпне 78 егет һәм кыз тәмамласа, сигезе медальгә лаек булган. Кагыйдә бозучылар юк. «Узган еллардагы нәтиҗәләр белән чагыштырмыйбыз. Кайсыдыр фәннән яхшырак, кайсыннандыр кимрәк. Рус телен бер укучы бирә алмаган иде, ул аны кабат тапшырды. Математика буенча – тәртип», – диде Илмас Хәмидуллин.

Татар теленнән республика сынавын нибары бер генә укучы сайлавы турында язып чыккан идек. Балтач районының Норма мәктәбе укучысы Әдилә Шәйхетдинова туган телдән имтиханнан 86 балл җыйган.

– Биремнәр бик авыр түгел иде, ләкин баш вата торган бер-икесе булды. Мин татар телен үзем генә бирдем, яшьләргә шуны әйтәсем килә: татар теленнән имтихан бирергә бер дә курыкмагыз! Телегезне онытмагыз, аны камилләштерегез, саклагыз! Минем шикелле туган телен яраткан, аның киләчәгенә ышанган кешеләр булганда, татар телебез дөньякүләм таралачак, – ди ул.

100 баллылар

БДИда 100 балл туплаган укучылар шактый. Рус теленнән иң югары баллны – 88, рус әдәбиятыннан – 39, химиядән – 24, математикадан (профиль) – 18, җәмгыять белеменнән – 13, тарихтан – 5, физикадан ике укучы җыйган. Шулар арасыннан сигез укучы ике фәннән 100әр балл туплаган.

Тәтеш районының Олы Тархан мәктәбен быел нибары 4 укучы гына тәмамлаган. Бессоново авылыннан килеп укучы Дарья Россееваның тарих фәненнән БДИ нәтиҗәсе – 100 балл. Әлеге мәктәптә бу беренче генә очрак түгел. Ике ел элек республикада географияне иң яхшы белүчеләрнең берсе дә шушы мәктәптән иде.

Дарьяны исә барлык фәннән дә көчле укучы дип мактыйлар. Инглиз телен яхшы белә. Бу фәннән бөтенроссия олимпиадасының республика этабында җиңгән. Мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган. Дарья биш фәннән БДИ тапшырган. Укытучылар белән дә әзерләнгән, өендә дә тик тормаган. Интернеттагы чыганаклардан да файдаланган.

– Тарихтан 100 балл туплавыма барысы да гаҗәпләнә. Моның сере нәрсәдә, дип кызыксыналар. Укытучымның һәм үземнең хезмәтем бу. Укытучым Миронов Евгений Сергеевич һәрвакыт хуплап, ышанычын белдереп торды. Шуның өчен дә югары балл туплый алдым, – ди Дарья. – Чынбарлыкта БДИ куркыныч әйбер түгел икән. Оештыручылар әйтмешли, тормыштагы бары бер сынау гына. Мәктәптә тырышып укыган һәркем аны тапшыра аладыр дип уйлыйм. Имтиханда тынычланырга һәм үз белгәннәреңне искә төшерергә генә кирәк. Кайсы вузга барасымны төгәл әйтә алмыйм. Барысы да имтихан нәтиҗәсеннән тора. Үзебездә калам, читкә китәргә җыенмыйм.

Казанның 18 нче гимназиясен тәмамлаган, рус теле һәм әдәбиятыннан сынауларда 100әр балл туплаган Эвелина Мөслимованың да хәлләрен белешеп алдык. Ул инглиз теленнән дә шундый ук күрсәткечләргә өметләнгән иде. Инглиз теленнән илкүләм олимпиаданың республика этабы призеры ул. 1 нче сыйныфтан 11гә кадәр бары «5ле» билгеләренә генә укыган. Теләге – КФУның лингвистика бүлегенә укырга керү.

Рус әдәбиятыннан сынауны ул ярты ел кала гына сайлаган. «Аллага шөкер, җайлы вариант эләкте. 100 балл туплавымны белгәч, шаккаттым. Рус теленнән 10 нчы сыйныфта ук әзерләнә башлаган идем. Аның нәтиҗәсе югары булачагына шигем юк иде. Икесеннән дә 100әр балл булгач, хәзер өченчесе дә шулай ук булсын иде дип көтәм. Юкса күңел төшәчәк. Мин үз алдыма югары максатлар куярга өйрәнгән», – ди ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Тормыш кыйпылчыклары


priumnojay.ru

Бу сезгә кирәк түгел!

План буенча билгеләнгән диспансерлаштыру үтеп алдым әле. Табиблар бик игътибарлы булды. Һәр белгечкә диярлек талон бирделәр. Алары тагын УЗИга-фәләнгә җибәрделәр. Шулай йөри торгач, тикшерелү озаккарак та китте. Баштарак бик кысан, шыксыз тоелган коридорларга да күз ияләшкән кебек булды. Кызык һәм кызганыч хәлләр дә очраштыргалады.

Бервакыт шулай коридор башындагы бәдрәфләр каршында урнашкан кабинетка керергә чират көтеп торам. Ак яулыклы бер әби килде дә, күзлеген киеп, әле ир-атлар бәдрәфе ишеге төбендә, әле хатын-кызларныкында әрле-бирле йөренә, таптана башлады. Үзе нәрсәдер сөйләнә. Күренеп тора: аңлап бетерми бу.

– Апа, сез нәрсәдер эзлисез бугай? – дим.

Әллә татарча эндәшкәнгә, әллә инде сорашырга кеше табылганга, әбинең йөзе яктырып китте.

– Кызым, монда туалет кайда соң? – диде ул, колагыма итагатьле генә пышылдап. Югыйсә тирә-юньдә кеше дә юк иде инде.

– Менә бит, – дим. – Шушы ишекләр инде.

Әбием, аңлаган сыман итеп, ә-ә, дип куйды да, җилҗил атлап, ир-атлар бәдрәфенә юнәлде. Артыннан куып тотып, тиз генә хатын-кызларныкына кертеп җибәрдем. Чыккач, ул, сораулар биреп, мине тагын тинтерәтеп аласы итте.

– Кайсы кызларныкы, кайсы ирләрнеке икәнен ничек белергә соң монда? – ди.

Ишекләргә түгәрәк һәм өчпочмак куелган бит инде. Аңлаешлырак булсын дип, аска таба киңәеп киткәне итәк кебек була инде, димәк, монысы кызларныкы, дип әйткән булдым. Әби, беренче күргәндәй, кем белә, бәлки, шулайдыр да, ишектәге «кыз» белән «малай»ны сыйпапсыйпап карады.

«Ә ник монда туалет дип язмаганнар соң?» – дип тагын сорау бирде. Язылган бит, монысы инглизчә дим, WC хәрефләренә төртеп күрсәтеп. Әбинең гаҗәпләнүдән күзләре шар булды.

– Ник безнең бүлнискә инглизләр дә йөримени? – диде ул, аптырап.

Башкалабыздагы элмә такталарның күпчелеге инглиз телендә булуы, ул түгел, яшьрәкләрнең дә аңлап бетермәве турында гәп куертып тормадым инде. Ни өчен дигән сораугa барыбер җавап бирә алмыйм бит.

Табиб яныннан чыгып, кайтыр юлга борылган идем. Әби тагын күземә чалынды. Талон алган да сканер янында басып тора. Әмма үткәрә алмый, чөнки кәгазьне сканерның экранына куя. Коридор буйлап күзәтеп киләм шулай: аптырап бетте бу. Мине күргәч, якын туганын күргәндәй, кәгазен кулыма тоттырды. Талонны сканер аша үткәреп, менә шушы номер зур экранга чыккач, кабинетка керерсең дип, әбине фойедагы утыргычка утыртып калдырдым.

– Кызым, син ачуланма инде, яме. Мин инглизчә белмим шул. Мәктәптә дә укытмадылар. Әле русчасын да ипи-тозлык кына беләм. Авылдан мин. Университетларда укырга туры килмәде инде, – диде ул, аклангандай итеп.

Укысаң да әллә ни майтарып булмый әле. Поликлиникадан чыктым да күршедәге йорт алдыннан узып барам. Моңарчы игътибар гына ителмәгән икән. Беренче катта урнашкан барлык оешмалар, кибетләрнең исемнәре гел инглиз телендә язылган. Аңлаганын аңладым, аңламаганын – юк. Миңа да инглизчә укырга туры килмәде шул. Әби әйтмешли, авылда чит телнең әсәре дә булмады, университетта гарәп теле керде. Чит илгә ял итәргә баргалый башлагач, әле ярый үзлегемнән азрак өйрәнгән идем. Кайчагында шуның файдасы тиеп куя. Ә болай инглиз телендә язылган элмә такталар: «Бу синең өчен түгел!» – дип чекрәеп торалар сыман. Ни икәнен белмәгәч, ишекне ачып керәсе җайсыз бит инде. Бәдрәфкә исә керми булмый.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

КӨНЕНӘ 300 ПАР ОЕКБАШ БӘЙЛӘҮЧЕ РАМИЛ ГАРИФУЛЛИН:

«Авыр эш түгел, җаен белгәч, тиз башкарам»

Егет кешегә җитмеш түгел, йөз җитмеш һөнәр дә аз. Кукмара районының Аш-Буҗи авылында яшәүче Рамил Гарифуллин әнә шулай ди. Авылдашлары, Рамил оекбаш бәйли, дигәч, баштарак аптырап киттек. Күз алдына төргәк-төргәк җепләр, зур энәләр килеп басты. Алай түгел икән.

– Элек күп итеп мал тоттык. Әмма мәшәкате күп. Печәнен әзерлисе, көтүен көтәсе бар. Әни дә әкренләп олыгая. Уйлаштык та, малларны сатып, оекбаш бәйли торган машиналар алдык. Аларны иске өйгә урнаштырып, көйләп куйдык, – ди Рамил. – Машина белән оекбаш бәйләгәнне телевизордан гына күреп калганым бар иде. Ялгыша-ялгыша булса да, бәйләргә өйрәндем. Дөресрәге, машиналарга җепне әзерләп куясың да, калганын үзе эшли. Берничә минут эчендә, башын ачык калдырып, оекбашны бәйләп тә чыгара. Аннары шуны икенче машинага кертеп, матур итеп тегеп куям. Оекбаш кыяфәте керә. Үтүкли торган җиһазым бар. Авыр эш түгел, җаен белгәч, тиз генә башкарам.

Рамил җепләрне читтән кайтарта икән. Санкцияләр комачау итмәгән үзенә. Киресенчә, доллар бәясе төшкәндә, чималны арзанга эләктереп калган.

– Төрле вакыт була инде. Кайчак табышы булып куя, кайчак югалтасың. Әмма күңел төшереп утырган юк. Кибетләр белән сөйләшеп, алар сатып бирә. Акмаса да, тама. Акчасыз утырганыбыз юк, – ди ул. – Әле менә быел суган утырта башладык. Бу эштә без әле өйрәнчек кенә. Авылдашларның күбесе суган үстереп акча эшли, тәҗрибәләре дә күп. Алардан калышмаска исәп.

Ә оекбашларга килгәндә, Рамил эш арасында гына булса да, көненә 300 пар оекбаш бәйли икән. Киләчәктә бу эшен тагын да җәелдермәкче әле ул. Алучысы гына булсын!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Файдалы казылмалар запаслары буенча дәүләт комиссиясе» федераль бюджет учреждениесенең Казан филиалы директоры урынбасары (Казан шәһәре) **Мотыйгуллин** Равил Хәйдәр улы **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Берлек» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Баулы районы) **Әхмәтова** Ландыш Зөлкарнәй кызына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитештерү-маркетинг бүлеге консультанты **Галләмов** Рафикъ Мөгътәсим улына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Гатиятов** Ренат Мансур улына, «Лысов Владимир Анатольевич» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Лысов** Владимир Анатольевичка, «Башак» агрофирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары (Татарстан Республикасының Тәтеш районы) **Мавлиханов** Ранис Фәрид улына, «Кыят» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директорының үсемлекчелек буенча урынбасары (Татарстан Республикасының Буа районы) **Нигъмәтуллин** Рафикъ Рафаил улына, «Низамов Альберт Әлфикъ улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы урынбасары (Татарстан Республикасының Чүпрәле районы) **Низамов** Дамир Әлфикъ улына, «Кызыл юл» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативы баш икътисадчысы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Сәгъзетдинова** Фәйрүзә Муллазыятдин кызына, «Щукина Рамилә Рифкать кызы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Кайбыч районы) **Щукина** Рамилә Рифкать кызына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

МӘКТӘПКӘ – ЯЛ ИТӘРГӘ

Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгыннан алынган мәгълүматларга караганда, республикада быел 842 мәктәп яны лагере ачылган. Аларда 57 меңгә якын бала ял итә. Болай да ел буе укып алҗыган балаларны кабат мәктәпкә кайту туйдырмыймы? Без Биектау районының Дөбьяз мәктәбендә оештырылган шундый җәйләүләрнең берсендә булып кайттык.

Анда ял лагерена – 70, хезмәт лагерена 30 бала йөри. Укытучылар кушканга түгел, үзләре теләп язылганнар. Укучылар саны быел күбрәк тә икән әле. Чыршы авылыннан да 12 бала килгән. Әйдаманнары – 8–9 сыйныф укучылары.

– Юк, мәктәп диварлары туйдырмый. Без аларны кызыксындыру юлларын эзлибез. 21 көннең берсе дә бер-берсен кабатламый. Элеккеге пионер лагереннан бер дә ким түгел. Иртән Россия, Татарстан әләмнәрен күтәрәләр. Бу – алар өчен үзе бер горурлык. Ничек өйрәтәсең, шулай гадәтләнәләр. Россия көненә мәктәптә махсус тәрәзә ясадык. Балалар макулатура да җыя. Иң күп кәгазь китерүчене бүләклибез. Алар мәктәпкә дип түгел, лагерьга дип килә. Көнгә өч тапкыр тукланалар, – ди тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Алсу Петрянкино. – Балаларга гадәти булмаган форма ошый. Урамга еш алып чыгабыз, төрле уеннар оештырабыз. Клубка кинога йөрибез. Ямаширмә авылына тәвә кошлары фермасына бардык. Биектауда яңа ачылган кинотеатрда булдык. Кече Солабаш авылында бер меценат «Хыял» ял паркы төзегән иде. Аны да күрмичә калмадык. Бу балаларга үз җирлегебезне белү өчен дә файдалы.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Без килгәндә, балаларның «Алло, без сәләтләрне эзлибез» дигән чарадан таралышкан чагы иде. Матур костюмнар киеп, җырлап, биеп күңел ачканнар. Балаларның күбесе музыка мәктәбенә йөри икән. Алдагы көнне генә Эшмәкәрләр көнен билгеләп үткәннәр. Укучылар һәркайсы үз хезмәтен тәкъдим иткән. Берәүләр үзләрен – чәчтараш, бизәндерүче, массаж ясаучы, икенчеләр таксист, пешекче ролендә сынаган. Коймаклар, төрле ризыклар пешереп алып килүчеләр дә булган. Кемгәдер сатучы, кемгәдер сатып алучы булырга туры килгән. Товарга бәя куеп, ташламалар да ясаганнар. Мәктәп исә аларга сатар өчен уенчык акча әзерләгән. Мондый уеннар укучыларны финанс белеменә өйрәтүне күздә тота. Кайсы роль күбрәк ошады дигәндә, укучыларның күбесе, акча эшләү, дип җавап биргән.

Бәйрәмнәрнең төрлесе бар. Әйтик, Нептун көнендә кашык белән стаканга су ташыйлар. Беренче булып тутыручыны билгелиләр. Соңыннан су сибешеп уйныйлар. Гиннесс китабына керү мөмкинлеге дә бар. Башкаларны шаккатырып, рекорд куючылар керә анда. Смена тәмамланганда, укучылар әйдаманнарның һәрберсенә рәхмәт әйтеп хат яза. Ял Сабантуй белән тәмамлана. Малайлар бил алыша, бергәләшеп аркан тартыша. Бәйрәмнән соң самавыр куеп, табигатьтә чәй эчәләр.

– Кызыбыз Айгөл 1 нче сыйныфны тәмамлады. Өйдә утырырга яратмый, шуңа күрә лагерьга бик теләп йөри. Күбрәк экскурсияләргә бару ошый аңа. Мәктәп дивары – мәктәп дивары инде ул. Рәсем ясап, уеннар уйнасалар да, каядыр бару кызыграк. Ямаширмәгә барып, тәвә кошы, дөяләр күреп кайттылар. Сменаның соңгы көннәре якынлаша. Кайбер балалар йөрүдән туктаган инде. Тик безнең Айгөл: «Әни, ник килмиләр инде, анда бит бик кызык», – ди. Яшь әйдаманнар булу да күңелле, – ди ике бала әнисе Сания Агаева.

Сәрия МИФТАХОВА

РӘХМӘТ СҮЗЕ

Кадерлебез Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллинның һич уйламаганда-көтмәгәндә арабыздан китеп баруы аяз көнне яшен суккандай булды. Сагынабыз, юксынабыз, әле һаман да күңел ышанмый. Иксез-чиксез илебезнең һәр төбәгеннән диярлек алынган кайгы уртаклашу телеграммаларының, телефоннан шалтыратуларның исәбе-хисабы юк.

Кадерлебезне көчле рухлы шәхес – оста оештыручы, тәҗрибәле җитәкче, сәясәтче, галим, милләтпәрвәр буларак бәялиләр, республикадагы иң актуаль мәсьәләләрне хәл итүгә, Россиядә дәүләтчелекне ныгытудагы биниһая өлешенә рәхмәтләрен җиткерәләр.

Без исә үз чиратыбызда Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановка, Беренче Президентыбыз, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәрип улы Шәймиевкә, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшинга, Премьер-министр Алексей Валерьевич Песошинга, хезмәттәшләренә, фикердәшләренә аңа булган хөрмәтләре, булышлыклары, ярдәмнәре өчен чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Дөньялар тыныч-имин, күк йөзебез аяз булсын!

Тормыш иптәше Рәдифә Сибагатуллина, туганнары, балалары, якыннары

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

«Татагрохим» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Наил Фарук улы Гобәйдуллин һәм «Татагрохим» ААҖ коллективы, Татарстан Республикасы элекке авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, V, VI, VII чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты

Фатыйх Сәүбән улы СИБАГАТУЛЛИН

вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

КОЯШ СӘГАТЕ БУЕНЧА ЯШӘҮ

Тәтеш

Түштән ярминкәсе, дәртле җыр-биюләр, телеңне йотарлык милли аш-сулар. Тәтеш районы Килдеш авылында мордва халкының «Валда Шиньяс» бәйрәме гөрләде. Һәр ел саен бирегә йөзләрчә кеше әлеге фольклор бәйрәмен тамаша кылырга килә. Быел инде ул тугызынчы тапкыр үткәрелде.

Кунаклар өчен кәсепчеләрнең Түштән ярминкәсе эшләп торды. Кунаклар аланында үләнле хуш исле чәй белән сыйладылар, мордвалар утарында халыкның күп гасырлар буе ничегрәк яшәве турында сөйләделәр, милли аш-суларын тәкъдим иттеләр. Ә инде балыкчылар рәтендә балык тоту сәләтен сынап карарга һәм өч төрле балык ашының тәмен татып карарга мөмкин иде. Олысы-кечесе күңелле спорт бәйгеләрендә, мордва халкының милли уеннарында катнашты.

Бәйрәм «Кояш сәгате буенча яшәү сәнгате» дип исемләнгән кереш өлештән башланып китте. Анда мордва халкының бай тарихы һәм гореф-гадәтләре, бәйрәм тарихы белән таныштырдылар.

– Валда Шиньяс бәйрәмен инде тугызынчы ел рәттән уздырабыз. Хәзер инде ул республика бәйрәме булып тора. Безнең район күпмилләтле. Һәр халыкның үз бәйрәме бар, – дип билгеләп үтте тәбрикләү чыгышында район хакимияте башлыгы Рәмис Сафиуллов.

Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре комитеты рәисе беренче урынбасары Илдар Гыйльметдинов исә «Валда Шиньяс» бәйрәменең Россия халыклары мәдәни мирасы елында бөтен Татарстан өчен мөһим вакыйга булып торуын билгеләп үтте. «Безнең бурыч – мәдәни байлыгыбызны киләчәк буыннарга тапшыру», – диде ул.

Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның котлавын укып үтте һәм районда яшәүчеләрне, кунакларны бәйрәм белән котлады.

Быел республика фольклор бәйрәменә Мордовиядән, Чуашстан, Казан, Ульяновск, Алексеевск, Кама Тамагы һәм Тәтештән талантлы иҗат коллективлары җыелды. Аларның барысы да «Мордва җыры агыла» концертында катнашты.

Елена КАЛАШНИКОВА

tetyushy.ru

Ленинград өлкәсе

25 июньдә Ленинград өлкәсенең Энколово авылында Сабан туен бәйрәм иттеләр. Татарстан исеменнән кунакларны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

– Элек-электән Сабан туен Татарстан һәм Башкортстанда гына түгел, илебезнең башка төбәкләрендә дә бәйрәм итәләр. Мәйданда кунакларның күп булуы шатландыра. Сабан туе халыкларны берләштерә торган бәйрәмгә әверелде. Нәкъ менә шундый бәйрәмнәр телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калырга ярдәм итә дә инде, – диде парламент башлыгы һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең сәламен җиткерде. «Без төрле, әмма без бергә – көчебез әнә шул», – диде Ленинград өлкәсенең вице-губернаторы Анна Данилюк.

Нева буендагы Сабан туеның 100 еллык тарихы бар. Тәүге тапкыр аны Санкт-Петербургтагы Юсупов бакчасында бәйрәм иткәннәр. Быелгы бәйрәмдә исә дистәләгән мең кунак күңел ачкан. Традицион уеннар, милли көрәш, Татарстан, Башкортстан, Ленинград өлкәсе һәм Санкт-Петербург сәнгать әһелләренең чыгышлары, милли ашлар… Энколово авылындагы мәйдан иртәдән кичкә кадәр гөрләп торган.

ИКЕ ТОННА АШ

ИСКЕ АРЫШ АВЫЛЫНДА ИЗГЕЛӘР РУХЫН ШУЛАЙ ИСКӘ АЛДЫЛАР

Балык Бистәсе

Балык Бистәсенең Иске Арыш авылында гарасатлар, бәла-казаларның беркайчан да булганы юк икән. Алга таба да күрергә язмасын. Авыл халкы моның сәбәбен ел саен «Изгеләр ашы» үткәрүдән күрә. Быел әрвахларга атап, 22 сарык, 36 тавык чалганнар. Болында пешкән саваплы шулпадан авыз итәргә ераклардан киләләр. Тик монда билгеле бер кагыйдәне белеп барырга кирәк. «ВТ» хәбәрчеләре дә авылның борынгы йоласы белән танышып кайтты.

Рухлар хакына

Иртәдән кичкә кадәр үткәрелә торган дини бәйрәмнең үз тәртибе бар. Көндез – хатын-кызларга, кич ирләргә генә килергә ярый. Шулай ук киенү әдәбенә дә зур игътибар бирелә. Әбиләр, апалар, ханымнар беркайчан да чәчен-башын тузгытып, кыска күлмәктән килми. Башларында – яулык, өсләрендә – озын итәк. Югыйсә укылган догаларның ияләренә барып ирешмәве бар. Изгеләр дигәнең кемнәр икән?

Авылның 900 елга якын тарихы бар. Зиратта күмелгән әрвахлар турында халыкта төрле сүзләр йөри. Риваятьләргә ышансаң, каберлектә туган җирен яклап сугышкан сугышчылар күмелгән.

– Иван Грозный гаскәренә каршы сугышкан изге җайдаклар каберлеге бу. Явыз Иван сугышчылары авылны басып алмакчы булган. Тик ап-актан киенгән берничә җайдак каршы чыгып, аларны авылга кертмәгән. Кызганыч, үзләренең гомерләре яуда өзелгән. Әлеге вакыйга турында әти шулай дип сөйли иде. Аларга бабалары әйтеп калдырган. Сугыш вакытында да изгеләр рухына аш уздыру гадәте туктатылмаган. Без дә кечкенәдән йөрдек. Элек атлар җигеп, тракторларда киләләр иде. Барысын да тәртиптә тоткан өчен Ринат хәзрәткә рәхмәт, – ди бәйрәмгә Казаннан кайткан Фирая апа Нәбиуллина.

Зират буендагы эскәмиягә чират тезелгән. Барысы да Зөләйха абыстай янына сәдака бирергә ашыга. Ә ул һәрбер хәер өчен дога кыла. «Изгеләр ашы»на алып килгән дөге, токмачны да иң элек монда алып киләсе.

Ирләр кулы тигән шулпа

Бу йоланы уздыру өчен атна буе әзерләнәләр. Гадәттә июнь ахырында үткәрелә бу аш. Кунакларны каршылау өчен махсус аланлыкны тәртипкә китерәләр. Янәшәдәге йортта мичкәләр, кирәк-яраклар тора. Изгеләр чишмәсе тирәсендәге үләнне чабалар, баскычны рәтлиләр. Халык җәй буе моннан су ташый икән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бәйрәм иртәсендә эш сәгать иртәнге алтыда ук кайный башлый. Ирләр, Аллаһ ризалыгы өчен дип, кош-корт, сарыклар чала. Узган ел авыл халкы корбанлык өчен 41 баш сарык биргән. Берничә хатын-кыз тавык йолкып тора. «Мин тавык йолкышырга ел саен йөрим. Үзем генә түгел, 4–5 кеше булабыз. Тавыклары бик әйбәт күренә», – ди Рушания Мингалиева.

Кайнар цехның пешекчеләре – ирләр. Аш-су әзерли торган учак янында зур утын әрдәнәләре өелгән. Мичкә белән су ташып торалар. Дүрт казанда да аш пешә. Тирә-юньгә борынны кытыклап, шулпа исе таралган.

– Бер казанга дүрт сарыкның итен салабыз. Ике тонна ашны халыкка таратып бетерәбез. Сәгать унга беренче шулпаны әзерләп куябыз инде. Күрше авыллардан да киләләр. Һәммәсенә – якты йөз, – ди пешекчеләрнең берсе Булат Зәйнуллин.

Аш пешерүне Хөрмәт абый Закировка озак еллардан бирле ышанып тапшыралар икән. Юллар төзүче абзый кухняда да менә дигән оста. Көн буе казан янында кайнашса да, арыдым, дигән сүзне әйтми. «Ите күп булгач, шулпасы да тәмле була. Дөгесен, токмачын барысын бергә салып пешерәбез. Илебезгә бәрәкәт теләп пешерәбез», – ди ул.

Кулларына бидон, банка, чиләк тотып килүчеләр дә күренә. Алар мәҗлескә килә алмаучыларның өлешен алып китә. Кыскасы, өлкәннәр дә, авырган кешеләр дә саваплы аштан авыз итә.

Авыл халкы исә аш белән сыйланып кына кылмый, ахирәтләре белән дә аралаша. Берәүләр килеп, икенчеләр китеп тора. Болында бергәләп, өйлә намазы укыйлар. Сәгать икеләргә кадәр хатын-кызларга килергә ярый әле. Аннан инде юк.

Берләшү

Сабан туена килгән кебек агыла монда халык. Оныклар иярткән әбиләр дә, кызларын җитәкләгән әниләр дә бар. Мәскәү, Чиләбе һәм башка шәһәрдә яшәүчеләр дә кунакка кайта. Халык бәйрәмне күтәреп ала, актив катнаша. Бер елны 150ләп машина җыелган.

– Мине дус кызым чакырды. Үзем Балык Бистәсендә яшим. «Изгеләр ашы»ннан авыз итәсе, игелекле Иске Арыш кешеләрен күрәсе килде. Мондый бәйрәмнәр күңелне кузгата, – ди Рәхия Мәсгутова.

Ак шәлен бәйләгән 95 яшьлек Хәтимә әби Гыйлаҗевага әллә каян күз төшә. Аны Акъәби дип йөртәләр икән.

– Күп еллардан бирле киләм, тик берничә ел җай чыкмады. Рәхмәт төшкере, улым алып килде. Тирә-якны шыпырт кына күзәтеп утырам менә. Кешеләр шулкадәр игътибарлы, бер-берләренә булган мөнәсәбәт сокландыра. Авыл хатын-кызларының йөзләре нурлы. Бу бик мөһим. Күңелләре иманлы, чиста дигән сүз бит бу, кызым. Авылны берләштерүче бик зур чара бу, – ди әбекәй.

…Хатын-кызлар өйләренә таралашып, кичке алты җиткәндә, болынга ирләр килә башлый. Аларга 150ләп урында табын корыла. Чирәмгә утырып аштан, иттән авыз итәләр. Аңарчы әрвахлар рухына дога укыйлар. Монда вәгазьләр укыла, теләкләр әйтелә.

– Хикмәте дә бар. Безнең авылда гарасат, җил-давылларның булганы юк, Аллага шөкер. Догабыз авылны саклый. Элек авыл зур булган, хәзер кими бара инде. Алга таба да дус-тату булып яшәргә язсын, – ди Ринат хәзрәт Габдуллин.

Сәрия МИФТАХОВА

Дөнья чемпионнары – Миңгәрдә

Саба

Саба районының Миңгәр авылында көрәш буенча дөнья чемпионнары ачыкланды. Егетләр быел келәмдә генә түгел, комлыкта да, атларга атланып та бил алышты.

27 илдән 200дән артык көрәшче чыгыш ясаган Дөнья чемпионатында үз категорияләрендә батыр булып Алексей Абрамов (Россия, Татарстан), Илназ Миңнуллин (Россия, Татарстан), Разил Шабиев (Россия, Башкортстан), 75тә Артур Зөлкарнәев (Россия, Башкортстан), Ренас Кәримуллин (Россия, Татарстан), Раил Сәлахетдинов (Россия, Татарстан), Илмир Төхвәтуллин (Россия, Татарстан), Айнур Сыртаев (Россия, Башкортстан), Радик Сәлахов (Россия, Татарстан), Турал Азимов (Азәрбайҗан) танылдылар. Баш батыр исемен исә Радик Сәлахов яулады.

Комдагы көрәштә җиңүче исемен Шамил Чәвик, Илнар Закиров, Динар Кәримуллин, Илшат Фазылҗанов, Рушан Ильясов, Фаяз Зарипов, Илдар Моратов һәм Фирдүс Зәйнуллин яулады.

17–18 яшьлек егетләр арасында узган дөнья беренчелеге ярышында исә Татарстаннан Илфат Миннегалиев, Рубин Рәҗәбов, Данис Садриев, Даил Зиннәтуллин, Илназ Шәмсиев, Данияр Моратов, Румиль Семкичев үз категорияләрендә беренче булды. Инсаф Хәйруллин икенче урынны алды.

«Татар-информ»

Кемерово өлкәсенең Новокузнецк шәһәрендә узган икенче шахтерлар Сабан туенда Баш батыр исемен Татарстан көрәшчесе Муса Галләмов алды. Баһадирга тәкә һәм Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның махсус бүләге – машина тапшырылды.

Бәлеш туе

Балтач

Яшьләр бәйрәмен Балтачта ел да зурдан кубып, ниндидер мөгез чыгарып үткәрергә яраталар. Быел халыкны иң җәлеп иткәне: 60 килограммлы борай бәлеше пешерү булды.

Әлеге идея авторы, милли ризыклары белән республикада танылып килүче Балтач эшмәкәре Альбина Фәсхиева белән шул хакта сөйләштек.

– Бельгиядә яшәүче Казан кызы Лилия апа Вәлиева социаль челтәрдә минем борай бәлешен күргән дә кызыксына калды. Безне үзләренә кунакка чакырды. Без анда барып, ике көн мастер-класс күрсәтергә тиеш идек. Әмма пандемия сәбәпле бара алмадык. Шул чакта ук күңелгә бөтен кеше дә борай бәлеше пешерми бит, нәрсәдер эшләргә кирәк дигән уй килде. Остазым, 50 ел җәмәгать туклануы системасында эшләгән, атказанган пешекче, Юныс Әхмәтҗановның укучысы Нурҗиһан апа Галимова белән киңәшкәннән соң шундый фикергә килдек. Район җитәкчеләре дә бу ниятебезне күтәреп алды. Башта 50 килолы бәлеш пешермәкче идек, аннан бер метр диаметрлы табага зуррак бәлеш тә сыясын исәпләдек. 71 килограммлы бәлеш булып чыкты. «Сабантуй» ял паркына район хакимияте махсус мич чыгарттырды, табаны ясатуда сөт-май комбинаты иганәче булды. Таба үзе генә дә 57 килограммга якын булды. Бәлешне өч кеше ясадык. 10 килограмм он, ун йомырка, 14 килограмм борай ярмасы, ун килограмм бозау ите, бишәр килограмм суган һәм сыер мае кирәк булды. Бәлеш дүрт сәгать пеште. Көрәшче егетләр аны мичтән алды, калын торбалардан ясалган махсус җайланма белән мәйданга алып керде. Халык бик яратып ашады, чын шулпалы бәлеш булып чыкты, – дип сөйләде ул.

Кызганычка, Россиянең рекордлар китабына керү дигән ниятләре генә әлегә барып чыкмаган. Заявка биргәндә бу эшнең коммерцияле булачагы турында уйлап бетермәгәннәр. Заявка өчен генә дә 225 мең сум акча кирәк булган. Вакыт калмаганлыктан, иганәчеләр табып өлгерә алмаганнар. Әмма Альбина һәм аның командасы чигенергә җыенмый. Бәлешне ашап бетергәнче үк инде, киләсе елга зур өчпочмак пешерәбез, дигән фикергә килгәннәр.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7057 данә
Гомуми тираж – 16016 данә

Газетага сертификат бирелде

Заказ 290

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+